ЧИСТАЙ ФЕРМЕРЫ:

«Хәзерге акылым булса, авыл хуҗалыгына борылып та карамас идем»

> 2

БАБАЙЛАР ЭЗЕННӘН

Татарстанда «Кайда икәнеңне беләм...» дип аталган яңа проект эшли башлады

> 3

МӘХӘББӘТТӘН – НӘФРӘТКӘ

Кариев театры Шекспир әсәренә яңа сулыш өрде

> 4

КҮЗГӘ КҮРӘШ

Федерация Кубогы ярышын Лаеш егетләре яулады

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 157 (28930) | Сишәмбе | 25 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КӨТӘР КЕШЕҢ БУЛГАНДА...

ТАТАРСТАНДА МОБИЛИЗАЦИЯЛӘНГӘН ЕГЕТЛӘРНЕ ХӘРБИ ЧАСТЬЛАРГА ОЗАТТЫЛАР

«Татар-информ»

Исән-сау әйләнеп кайтыгыз! Узган ял көнендә «Казан Экспо» мәйданчыгында бертавыштан әнә шундый теләк яңгырады. Бу көнне бирегә мобилизацияләнгән егетләрнең 721 кешедән торган беренче эшелонын хәрби әзерлекнең киләсе этабына озаттылар. Егетләр Россиянең Үзәк хәрби округы территориясендә урнашкан хәрби частька юл тотты. Алар анда корал, техника алачак һәм хәрби әзерлекнең чираттагы этабын узачак. Татарстан Хөкүмәте егетләрнең гаиләләренә ярдәм итү өчен яңа карар чыгарды.

Егетләрне озаткан көнне «Казан Экспо» тирәсендә алма төшәрлек тә урын юк иде. Якыннары, туганнары, газизләре белән күрешеп, олы юлга хәер-догада озатып калырга җыелды. Сахнәдән аларның рухын ныгытырлык, көч-куәт өстәрлек сүзләр шактый яңгырады. Казанда яшәүче Мәрьям ханым да улына сүз белән дә, наз белән дә көч-куәт өстәргә тырыша.

– Бик борчылам инде. Улым заводта токарь булып эшләде. Повестка килгәч, гаҗәпләнмәдек. Чакыралар икән, димәк, барырга кирәк, дидек. Улым да каршы килмәде. Качып йөрү турында уйламады да. Күңел бары яхшыга гына өметләнә. Балаларыбыз, ир-атларыбыз исән-сау әйләнеп кайта күрсен, – ди ул.

«Тормышка карашым үзгәрде»

Теләчедә яшәүче Шәйдуллиннарның бүген шатлыклары әченә сыймый. Бер төн эчендә тормышлары 180 градуска үзгәргән аларның. Мобилизациягә эләккән өч бала атасы Илсурны өенә кайтарганнар. Узган ялда Татарстан Чакырылыш комиссиясе нигезендә мобилизациядән азат ителгән күпбалалы әтиләрнең берсе ул. Илсур да, аның гаиләсе дә әле дә шок хәлендә. Төпчек кызы әтисен аеруча сагынып көткән. Әтисе өйгә кайтып керешкә, аның алдыннан да төшмәгән. Илсурның телефонының да тынып торганы юк. Аны белгән, хәтта белмәгән кешеләр дә котлый, сөенечен уртаклаша икән.

– Соңгы минутка кадәр бер нәрсә белмәдек. Әмма ахыргы көннәрдә бераз сизенә башлаган идем инде. Ник дигәндә, беренче батальон киткәндә күпбалалы әтиләрне автобустан төшереп калдырганнар дигән хәбәр ишетелгән иде. Аннары 22 октябрьдә «Казан Экспо»дагы күпбалалы әтиләрне җыеп, гариза яздырдылар. Әмма өздереп берни дә әйтүче булмады. Китәр көн җитте, хәбәр юк. Өметне өзгән идек инде, – дип сөйләде Илсур «ВТ» хәбәрчесенә.

«Казан Экспо»дан китәргә тиешле көнне Илсурны озатырга дип Теләчедән хатыны, балалары, якыннары килә. Алар белән бик озак кына сөйләшеп утырганнан соң Илсурның телефоны зарядкада калганлыгы исенә төшә. Шуны алырга дип кергән җирдән хәрби комиссариат кешесе: «Шәйдуллин син бит инде? Кайтаннан бирле сине эзлибез, үзең генә калдың», – дип кычкырып җибәргән. Аңа әйберләрен җыярга кушалар. Хәрби билетын кулына алып, башка күпбалалы әтиләр белән автобуска төяләшәләр дә, танк училищесына барып әйберләрен тапшырып, өйләренә кайтырга чыга алар. Теләчедән – 2, Сабадан 5 күпбалалы әтине кире өйләренә кайтаралар ул көнне.

Илсур повестканы 23 октябрьдә алган. Өч көннән җыенып китәргә дә туры килгән аңа. «Казан Экспо»да яшәгән бер ай эчендә бирдәге егетләр белән дуслашып, бер гаиләгә әверелгән алар. Социаль челтәрләр аша Илсур безнең дә туганыбыз кебек якын кешебезгә әверелде. Язылучылар каршына һәрчак көләч йөзле, оптимист булып чыга иде ул. Шунда ук матур итеп җырлап та җибәрә. Мобилизациягә бәйле сорауларга җавап бирергә дә өлгерә:

– Анда борчылып тик утырсаң, үз-үзеңне ашап кына бетерәсең. Җырлапмы, сөйләпме – ничек булса да кәефеңне күтәрергә кирәк. Социаль челтәрләр аша мобилизация турында файдалы мәгълүмат та биреп барырга тырыштым. Юкса без киткәндә берниндиди мәгълүмат юк иде. Төймәле телефонны гына алган идем. Анда заманчасы яраган икән. Шуңа күрә менә шундый нечкәлекләргә кадәр аңлатырга, җиткерергә тырыштым егетләргә. Әле бүген дә рәхмәт сүзләре килә, – ди Илсур.

Бер ай эчендә тормышка карашы да үзгәргән аның.

– Аллаһы Тәгалә миңа бу сынауны мин яшәү, тормыш кадерен аңласын өчен җибәргән. Гаиләгә, дусларга карашым бөтенләй икенче хәзер. Бер-береңә авыр сүзләр әйтмичә, бер-береңнең, тормышның кадерен белеп яшәргә кирәк икән. Гади тормышның һәр мизгеле, рәхәтләнеп тоям. Повестка алган кешеләргә, якыннарына түземлек, сабырлык телим. Аллаһы Тәгаләдән сорарга кирәк. Ничек кенә булса да өметне өзмәскә, мобилизациягә эләккән егетләрне җылы сүзләрне кызганмаска кирәк, – ди Илсур Шәйдуллин.

Ахыры 2 нче биттә >

kzn.ru

Мәктәптә тынычрак булачак

Быел Казанда 281 мәгариф оешмасының коймалары алыштырылачак. Бу максатка 992,2 миллион сум бирелгән. 244 оешмада әлеге эш башкарылган да инде. Калган 37сендә аны ноябрьгә кадәр төгәлләү көздә тотыла. Татарстан башкаласында барлыгы 533 мәгариф оешмасы: 169 мәктәп, 312 балалар бакчасы, 52 өстәмә белем бирү учреждениесе эшләп килә. Алар барлыгы 654 бинага урнашкан. 40 процентының коймалары нык тузган яки бөтенләй булмаган.

181 мәктәп һәм балалар бакчасы биналарының беренче катында видеокүзәтү, сак сигнализациясен, куркыныч турында кисәтү җайланмаларын урнаштыру бәйле эшләр тәмамланып килә. Моның өчен 39 миллион сум бирелгән. Моннан тыш, 22 мәктәптә контроль-кертү пунктлары булдырылачак. Моның өчен 71 миллион сум акча тотылачак.

Инде килеп, Телекоммуникацияләр технологияләре департаменты мәгариф оешмаларын 746 видеокүзәтү камерасы белән тәэмин иткән. Ел ахырына кадәр тагын 652 камера урнаштырылачак.

Хезмәт хакына кадәр

Сентябрь аенда Татарстанда хезмәт хакына кадәр дип алына торган һәм суммасы 30 мең сумнан артмаган 76130 микрозайм бирелгән. Бу – алдагы ай күрсәткеченнән 6,1 процентка кимрәк. Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматларына караганда, сентябрь аенда бирелгән микрокредитлар саны буенча республика ил төбәкләре арасында – алтынчы урында. Беренче бишлеккә Мәскәү (141693 займ), Мәскәү өлкәсе (121812), Краснодар крае (94799), Свердловск өлкәсе (91698) һәм Башкортстан (87147) кергән.

Бюро мәгълүматлары буенча, Россиядә яшәүчеләр сентябрь аенда барлыгы 2,59 миллион микрозайм (алдагы айдагыга караганда 5,8 процентка кимрәк) алган.

Ике районда – карантин

Татарстанда ике районда, кабан дуңгызларында Африка дуңгыз чумасы табылу сәбәпле, карантин кертелгән. Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән тиешле Указны имзалаган. Чир чыганагы Әлки районының ау биләмәләрендә һәм Питрәч районындагы «Радуга» ау хуҗалыгы территориясендә табылган.

Указ нигезендә Әлки районындагы – 38, аның куршесендә урнашкан Спастагы – 14, Питрәчтәге – 44, аның куршесендә урнашкан Лаештагы – 17 һәм Балык Бистәсендәге 8 җирлек куркыныч янаган урыннар булып исәпләнә. Гомумән алганда, республикадагы 24 районда иминлек чаралары күреләчәк. Алар күзәтү зонасына эләккән.

Суыта

Октябрь ахырында Татарстанда көндезге һава температурасы 0 градустан түбәнгә төшәчәк. Республика Гидрометеоүзәге фаразы шундыйрак.

Чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе – 26–27 октябрьдә явым-төшем көтелми. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –1...+5 градус күрсәтәчәк. Төнлә +1...–6. Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда җомга – 28 октябрьдә Татарстанда яңа явырга һәм көн кар явачак. Шимбә – 29 октябрьдә урыны белән, асылда көнчыгыш районнарда, аз гына явым-төшем фаразлана. Атна ахырында көндез +3...–2 градус көтелә. Төнлә һәм иртән юлларда бозлавык булырга мөмкин.

Яңалык

Ковид китсә, грипп бар

Берсен алып, икенчесен куярлык түгел. Коронавирус белән грипины үзара чагыштырып, кайсының зыянлырак икәнен фаразларга яратучыларга белгечләр шулай ди. Икесе дә мәкерле, вакытында дәваланмасаң, икесе дә аянычлы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Сезонлы вирус авырулары котырган көзге чорда аеруча сак булырга кирәк, дип кисәтә белгечләр.

Билгеле булганча, Татарстанда коронавирус белән авыручылар саны инде өченче атна рәттән кими бара. Беренче тапкыр бу күренеш сентябрьнең соңгы атнасында күзәтелгән иде. Ул чакта республикада коронавирус белән авыручылар саны 19 процентка кимеде дип хәбәр ителде. Узган атнада исә ковид белән авыручылар саны 32 процентка кимегән. Бу юлларны язганда Татарстанда соңгы бер тәүлек эчендә ковид йоктыручның 155 очрагы теркәлгән иде.

Гомуми практика табибы Гөлназ Бәдретдинова сүзләренә караганда, соңгы арада хастаханәләрдә коронавирус диагнозы, дөрестән дә, азрак куела башлаган.

– Коронавирус хәзер без күрергә күнеккән билгеле вируслы авырулар рәтенә кереп бара. Күпләрдә ул хәзер ОРВИ рәвешендә генә уза. Чирне берниндиди билгеләрсез генә уздыручылар да шактый. Шәхсән үземә мөрәҗәгать итүчеләр арасында колак авыртудан зарланучылар да булды. Бу – шулай ук коронавирусның бер билгесе. Коронавирус белән авыручылар саны кимесә дә, тынычланырга ярамый. Сезонлы вирусны чирләр котырган чорга кердек бит. Берсе булмаса, икенчесен йоктырырга мөмкин. Сакланырга кирәк, – ди табиб.

Саклану дигәндә, инде соңгы елларда ятлап бетергән гади генә кагыйдәләрне атый ул: битлектән йөрү, гигиена кагыйдәләрен үтәү, авырга каршы вакцина ясату. Соңгысы әлегә елдагыча аксый бирә. Рәсми саннардан аңлашылганча, бүген республикада 1926123 кеше коронавируска каршы вакцинаның ике компонентын да

Илдар Мөхәммәтҗанов

ясаткан. Шуларның 524965е генә ревакцинация узган. Бу – калган 1,4 миллион чамасы кешегә коронавирус йоктыру куркынычы яный дигән сүз.

Яшерен-батырын түгел, тормышыбызда коронавирус пәйда булгач, грипп дигән чир бермәлгә онытылып торды. Кайчак ул бөтенләй юкка чыккандай кебек үк тоела иде. Әмма белгечләр моны ялгыш фикер дип кисәтә. Татарстанның баш иммунологы Дмитрий Лопушев сүзләренә караганда, грипп – коронавирус кебек үк мәкерле чир. Сакланмаган очракта, аның нәтиҗәләре дә бик аянычлы булырга мөмкин.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз



Резеда СӘЛӘХОВА, Кәрим Тинчурин театры артисты:

Хәзерге спектакльләрнең фантигы бик матур, ә нәрсә турында барганлыгы аңлашылмый. Театр тамашачыларе: «Аңламагансың икән, син үзең аңгыра, үсеп җитмәгәнсең», – диләр. «Аңлашылмаганрак итеп куйган саен, режиссер даһирәк» дигән тенденция китте. Бу әйбер белән мин килешә алмыйм. Минем өчен мәгънә, фикер мөһимрәк.

(«Интертат»)

РОССИЯДӘ – ФӘН ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҮСЕШЕ

«РИА Рейтинг» агентлыгы фән һәм технологияләр үсеше буенча төбәкләр рейтингын төзегән. Исемлек төзегәндә төбәктәге фәнни активлык, ачышлар, инновацион товарлар җитештерү исәпкә алынган.

1 – Мәскәү – 79,61 балл	
2 – Санкт-Петербург – 76,78 балл	
3 – Татарстан – 68,06 балл	
...	
27 – Чувашстан – 43,68 балл	
...	
85 – Ингушетия – 9,51 балл	



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ МОГҖИЗАСЫ ТӨГӘЛЛӘНЕРМЕ?

Үткән атна вакыйгалары бик тыгыз һәм киеренке ак-тылар. Британиядә яңа гына Премьер-министр ка-мытын кигән Лиз Трасс отставкага китте. Ил та-рихында бу кадәр кыска вакыт һәм уңышсыз идарә иткән лидер юк иде әле. Аннан «Яңа Тэтчер» килеп чыкмады.

Хәзер британнар чираттагы Премьерны көтә. Сайлау алды узышы бара инде. Ярышка элекке Премьер-ми-нистр Борис Джонсон, элекке казна җитәкчесе Риши Су-нак һәм элекке оборона министры Пенни Мордонт кушылды. Әмма Хөкүмәтне җитәкләргә яраткан Джон-сон якшәбе көнне үз кандидатурасын алды, чөнки Су-нактан бик нык артка калуын аңлады. Элекке финанс министрының яңа Премьер булачагына хәзер беркем дә шикләнми. Имештер, Англия королевасы Сунакны индус булганы өчен бер дә яратмаган: «Мин исән вакытта им-перияне индус җитәкләмәячәк», – дип әйткән булган, диләр. Хәзер королева юк инде.

Вакыйгаларның иң кызыы һәм интригалысы Кытайда барды. Пекинда Кытай компартиясе җыены үз эшен тө-гәлләде. Си Цзиньпин өченче тапкыр Үзәк Комитетның генераль секретаре итеп сайланды. Шулай булачагы ал-дан ук мәгълүм иде инде. Компартиядә кабул ителгән ике сроктан артык сайланмау кагыйдәсенең бозылачагы, Синың өченче срокка барачагы беркем өчен дә сер бул-мады. Әмма съезд шома гына узмады. Компартиянең 2012 елга кадәрге лидеры Ху Цзиньтао Сины тәнкыйть-ләп чыгыш ясарга теләгән икән, имеш, дигән сүзләр та-ралды. Рәсми мәгълүмат кырына чыкмады алар. Әмма Цзиньтаоны съездның тантаналы рәвештә ябылу уты-рышы вакытында президиумнан этеп-төртеп чыгарган-нары, аның каршылык күрсәтеп маташуы төшерелгән видеоны телгән һәркем карый ала.

Компартиянең Үзәк Комитетында моннан соң Сига берсүзсез буйсынган кешеләр генә кала. Аңа оппозиция-дә булган «комсомоллар» дип йөртелгән төркемнән бер-кем дә юк. Кытайны өйрәнүче белгечләр – Көнбатыш һәм япон сәясәтчеләре моңа бик гаҗәпләнә, егерме ел буе Кытай белән идарә иткән төркем көтмәгәндә һәм бе-рьюлы хакимлектән читләштерелде, диләр. Моны Кытай могҗизасының төгәлләнүе дип аңлаталар. Чыннан та, Күк асты илендә икътисади хәл бик начар. Синың кәнә-фигә ябышуы һәм үз янына бары тик ләббәйкә әйтеп то-ручыларны гына җыюы – шуның билгесе. Идарәсе бик уңышсыз булган лидерлар гадәттә нәкъ шулай эшли, дилбегәне кулдан ычкындырудан куркалар.

Синың идарәдә калуы чиннар өчен генә түгел, бу ил-ларны язучылар һәм укучылар өчен дә зур әһәмияткә ия. Бу дөньякүләм вазгыятьнең начараюына китерәчәк. Гамәлдәге лидер – АКШ белән конфронтация тарафдары, Тайваньны хәрби юл белән Кытайга кушарга омтылучы. Съездда Кытай компартиясе үз уставына Тайваньның бәйсезлегенә каршы тору турындагы статья кертте. АКШ Хәрби диңгез көчләре адмиралы Майк Гилдей: «Кытай-ның Тайваньга бәреп керүе якындагы айларда ук мөм-кин», – дип белдерде. Бу юлларның авторы: «Конфликт ихтималлыгы бар, әмма зур түгел», – дип фаразлый. Кы-тай икътисадында хәлләр бик начарайганда гына сугыш башларга мөмкиннәр.

Россиядә

АКЫЛ КИРӘК

«Российская газета»ның телеграм-каналы Курск өлкәсен-дә өч оборона сызыгы төзелү турында рәсми хәбәр бир-де. Шундый ук чыгытмалар Белгород өлкәсендә дә тө-зелә. НАТОны 1997 елгы чикләргә кадәр алып ташлау хыялы әлегә барып чыкмады. Киресенчә, фронт сызыгы көнчыгышка таба күчә.

Үзәк разведка идарәсенең элекке директоры һәм Әф-ганстандагы АКШ һәм НАТО көчләренең элекке җитәкче-се Дэвид Петреус: «АКШ һәм башка илләр Россиягә кар-шы теге яки бу рәвештә НАТО көчләре буларак түгел, ә АКШ җитәкчелегендә күпмилләтле көч буларак чыгыш ясый алалар», – дип белдергән. Американнарның кеше ку-лы белән утлы күмер чүпләргә яратулары күптән мәгъ-лүм. Күрәсең, Вашингтонда тагын бер тапкыр Россиягә каршы зур коалиция оештыру идеясе туып килә. Россия өчен бик куркыныч идея бу. Путинның Астанадагы бел-дерүен искә төшерик әле: «НАТО гаскәрләре белән Рос-сия армиясенең турыдан-туры бәрелеше – бик куркыныч адым, ул глобаль катастрофага китерәчәк. Андый адымга бармаска акыл җитәр дип өметләнәм», – дигән иде ул 14 октябрьдә.

Әмма вакыйгалар кызулананнан-кызулана, океан ар-ты ягында акыл эзләп мәшәкатьләнмиләр. Россиянең АКШ-тагы илчесе Анатолий Антонов АКШның Россия белән сөйләшүләр өчен ике шарт куюын белдерде: беренчесе – гаскәрләрне 1991–2013 елгы чикләргә чыгару. Икенчесе – Россиянең репарация түләве. Мондый таләпләр тар-мар ителгән дәүләтләргә генә куела. Көнбатыш дәүләтләр Украинага 126 миллиард долларлык ярдәм күрсәткәннәр. Бу – хәйрия акчасы түгел, билгеле. Көнбатышлылар үзләре тоткан акчаны артыгы белән кайтарып алырга яраталар. Бу очракта Россиядән түләтмәкчеләр.

Россиянең оборона министры Сергей Шойгу үткән ат-нада атом-төш державасы булган дәүләтләрнең һәм Төр-киянең оборона министрлары белән телефоннан сөй-ләште һәм, Украина «пычрак бомба» кулланырга җыена, дип аларны кисәтергә теләде. Ул шартласа, шартлау дул-кыны булмый, әмма туфрак радиациядән зарарлана. Ки-ев Шойгуның ул фаразларын кире кага, бездә андый бомба юк, Россия үзе эшләячәк эшне безгә яга, дип бел-дерә. Андый бомба котчыккыч зур зыян салмый ул үзе, туфракны чистартып та була, әмма аның куркынычы шунда: ул шартласа, НАТО блогы Россияне гаепләп, кумәк һөҗүм өчен сылтау итә ала. «Российская газета» сайты дошмәбе көнне «АКШ, Британия һәм Франция Украинаның «пычрак бомба» куллану ихтималын кире каккалар» дигән кыска хәбәр урнаштыра. Димәк, бомба шартласа, кемне гаепләячәкләре билгеле. Хәлләр торган саен киеренкеләнә бара. Каховка ГЭСы дамбасының шартлау куркынычы турсендә дә бәхәсләр шул рәвешле. Мәскәү дамбаны украиннар шартлатырга тели дип бара, Киев Россияне гаепли. Көнбатышта, аңлашыла инде, Киев позициясен яклыйлар.

БИРЕГӘ ЭЛӘГҮ – ЗУР БӘХЕТ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Уфага эшлекле сәфәр кыла. Парламент башлыгы Чувашия Дәүләт Советы Рәисе Леонид Черкесов белән Уфа дәүләт нефть тех-ник университетында булды. 75 ел буе диярлек нефть һәм нефть эшкәрту тар-магына югары квалификацияле бел-гечләр әзерләүче вуз бу. «Татнефть»нең 250дән артыграк топ-менеджеры нәкъ менә шушы уку йортын тәмамлаган.

Фәрит Мөхәммәтшин үзе дә нефть институтында белем алган: Дәүләт Со-веты Рәисе 1979 елда биредә «инже-нер-механик» нефть, газ сәнәгате ма-шиналары һәм җиһазлары» белгечле-генә ия булып, берникадәр вакыт дәва-мында «Әлмәтнефть» булекчәләрендә эшләгән. Парламент башлыгы югары уку йорты мөгаллимнәре белән ара-лашып, институтта укып йөргән елла-рын бик җылы итеп искә алды, профес-сорлар, доцент һәм укытучыларга рәх-мәт белдерде.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үт-кәнчә, нефть институты киң колачлы фәнни, мәгариф проектларын гамәлгә ашырып, заман белән бергә атлый. Та-тарстан һәм Чувашия парламентлары башлыклары технология факультеты-ның уку корпусы, нефть химиясе про-цесслары технологияләре, нефть һәм нефть продуктларын анализлауның фи-зик-химик ысуллары лабораторияләре белән танышты.

«Кайда гына эшләсәм дә, универси-тет мөгаллимнәрен һәм галимнәрен һәрвакыт сагынып искә алам. Уфа нефть институты инде шул чагында ук нефтьчеләр әзерләү буенча илдә иң яхшы вузларның берсе булып торды. Бирегә эләгү зур бәхет иде. Хәзер күп нәрсәләр үзгәргән. Кадрлар әзерләү бер урында таптанып тормый, таләпләр дә арта, бүгенге шартларда көндәшлеккә сәләтле булу да кирәк. Татарстан һәм Башкортстанда нефть чыгару, нефть эшкәрту һәрвакыт икътисадның төп тармаклары булып тора, һәм без биредә белем алып чыккан кадрларны югары бәялибез», – диде Фәрит Мөхәммәтшин журналистлар белән аралашканда.

Очрашуда УГНТУ президенты Айрат Шаммазов Фәрит Мөхәммәтшинга әлеге уку йортында укып чыгучыларга бирелә торган мактау таныклыгын тапшырды.

Ковид китсә, грипп бар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Коронавирусның беренче дулкынында республика халкы үзизоляция шартларын-да яшәде. Битлекне дә салмыйча киделәр. Ул чорда гриппка каршы вакцинация дәрәҗәсе дә югары булды. Нәтиҗәдә ел дәвамында бер грипп йоктыру очрагы да теркәлмәде. Әмма узган ел вазгыять кискен үзгәрде. Халык иркенәйде, ты-нычлана төште. Гриппка каршы вакцина ясатучылар да азайды. Шул рәвешле грипп кабат әйләнеп кайтты, – дип сөйләде Та-тарстанның баш эпидемиологы.

Әлегә республикада грипп йоктыруның бер генә очрагы да теркәлмәгән. Узган ел шундый беренче очрак 25 октябрьдә ачык-ланган булган. Шуңа күрә белгечләр хәзер бу чирне кисәтеп, алдан аяк киеңү өчен менә дигән вакыт, ди. Бүген республикага гриппка каршы вакцинаның 1368660 доза кулланмага яңа партиясе кайтарылган. Хә-зергә вакытта барлыгы 827 меңнән артык кеше гриппка каршы вакцина ясаткан. Ел азагына кадәр аларның саны 2,4 миллионга җитәр дип планлаштыралар.

– Грипп һәм коронавируска каршы вак-цинаарны икесен бер көнне ясасаң да ярый. Организмның үзенчәлекләрен исәпкә алып, бу мөмкин түгел икән, алар арасында бер ай вакыт узарга тиеш. Гриппка каршы вакцина ясаткач, кешенең температурасы күтәрелер-гә, энә кадалган җир кызарып торырга, авы-ртырга мөмкин. Әмма бу билгеләр – вакыт-лы күренеш, алар бер тәүлектән соң юкка чыгачак, – ди эпидемиолог.

Гриппка каршы вакцинаны республика-ның барлык хастаханәләрендә, Казанда «Южный» сәүдә үзәгендә, метро яннарында эшләүче күчмә вакцинация пунктларында ясатырга мөмкин.

Сезонлы вирусы авырулар баш калкыткан чорда белгечләр түбәндәге киңәшләрне истән чыгармаска куша:

✓ чирне үзлегеннән генә җиңәргә маташу – зур хата. Авыруның беренче билгеләре күзәтелә башлауга ук та-бибка мөрәҗәгать итегез. Нинди дару эчеп, ни рәвешле дәваланасын фәкать ул гына хәл итәргә тиеш;

✓ урамга, кеше күп җыелган урыннарга чыкканда бит-лек киярг онытмагыз;

✓ урамнан кергәч, кулларны, битне яхшылап юыгыз. Өс киемегезне җилләтергә әлегез;

✓ бүлмәләрне даими рәвештә җилләтеп торыгыз;

✓ аз гына юталли, тамагы авырта башлауга, күпләр им-бир, лимон, бал кебек ярсыткыч продуктлар белән дәва-лана башлый. Алар исә, киресенчә, лайлалы тышчаны та-гын да ялкынсындыра;

✓ тамак авыртканда күпләп су эчсәгез, хәлегез тизрәк уңайланыр.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гаиләләрен дә ташламыйлар

Җылы сүз генә түгел, ярдәм дә булачак. Җомга көнне Хөкүмәт йортында Татар-стан Президенты Рөстәм Миңнеханов уз-дырган киңәшмәдә республикада моби-лизациягә эләккән кешеләрнең гаиләләренә ярдәм итү чаралары турын-да сөйләштеләр. Президент үз чыгышын-да мобилизациягә эләккән кешеләрнең гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чара-ларын билгеләүче Татарстан Хөкүмәте карарына кул куелуын билгеләп үтте.

– Өстәмә ярдәм чаралары һәр балигъ булмаган балага 20 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү, балалар лагерьларына бушлай юлламалар, урта һәм урта махсус уку йортлары укучылары һәм студентлары өчен бушлай кайнар туклану, балалар бакчасына түләүдән азат итүдән гыйбарәт. Алга таба без мо-билизацияләнгән кешеләрне транспорт салымын түләүдән азат итүне дә күздә тотабыз. Дәүләт Советы бу мәсьәләне ка-рады, без законга кул куячакбыз, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Эш җәйга салын-сын өчен, район башлыкларын хәрби ко-миссариатлар белән берлектә кыска вакыт эчендә үз зонасында булган, моби-лизацияләнгән, сугыш хәрәкәтләре зона-сыннан кайткан хәрби хезмәткәрләрнең, югарыда телгә алынган барлык катего-рияләргә гаиләләрнең, әлбәттә, һәлак бул-ганнарның гаиләләрен дә кертеп, реестр-ларын төзүләрен үтенәм.

Президент һәр гаиләгә барырга, алар-га нинди ярдәм кирәклеген ачыкларга, волонтерлык штаблары эшен оештыры-рга, адресы ярдәм чаралары күрергә кирәклеген дә искәртте.

Татарстан Премьер-министры Алек-сей Песошин тарафыннан имзаланган документтан аңлашылганча, мобилиза-циягә эләккән егетләрнең яңа туган бала-ларына кирәк-яраклардан торган бүләк комплекты тапшырылачак. Аларның гаи-ләләрендәге лаеклы ялда булган 60 яшь-лек ир-ат һәм 55 яшьлек хатын-кызлар ял йортына юлламаны беренчеләрдән бу-лып алырга хокуклы.

Хәрби бурычын үтәргә алынган ир-ат-ның гаиләсендәге өлкәннәр, шулай ук I һәм II төркем инвалидларга йорт шарт-ларында бушлай социаль хезмәт күрсәте-лергә тиеш. Моннан тыш әлеге төркемгә керүчеләр картлар яки инвалидлар йор-тына, психик тайпылышлы кешеләр өчен интернатка, балалар һәм үсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә урнашканда өстенлеккә ия булачак.

Дәүләт һөнәри белем бирү оешмала-рында урта звеноны әзерләү программа-сы буенча көндезге бүлектә укучы сту-дентлар уку йортында бер тапкыр бушка ашый алачак. Мобилизациягә эләгү-челәрнең мәктәптә укучы балалары исә ике тапкыр (иртәнге һәм көндезге аш. – **Ред.**) бушлай ашаячак. Моннан тыш мо-билизацияләнүчеләрнең 7–17 яшьлек ба-лалары ял оешмаларына юллама алганда да өстенлеккә ия булачак.

Эшсез дип табылган гаилә әгъзалары-ның бизнес планнары да өстенлекле рәвештә каралачак.

Әни җылысы кирәк

Халык та битараф түгел. Өлешчә мобили-зация игълан ителгән беренче көннәрдән үк Татарстанда егетләргә ярдәм җыю эше оештырылды. Бу изге эшкә һәркем кулын-нан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Кем-дер җылы оекбаш-бияләйләр бәйли, кем-дер егетләргә көндәлек кирәк-ярак юллап җибәрергә тырыша. Аларны гуманитар ярдәм җыю пунктларына илтеп тапшыры-рга мөмкин. Мондый махсус урыннарның адресы һәм эш графигы белән «ярдәм.рф» сайтында танышырга мөмкин.

Егетләрнең тамак ягын да кайгырта-лар. Әле бу көннәрдә генә мобилизациягә эләккән егетләргә 2 меңнән артык пирог тапшырганнар. Казанның танк училище-сында хәрби әзерлек узучы егетләр бу тәм-томнардан авыз итәргә дә өлгергән. Аларны «Әнием пироглары» дип исем-ләнгән акция кысасында Татарстанның 30 районында пешергәннәр. Казан, Яшел Үзән, Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама һәм Ала-бугада яшәүче гүзәл затлар егетләргә пироглар пешерсә, Арча, Тәтеш, Сарман, Кукмара, Мамадыш уңганнары чәкчәк, бавырсак ише тәм-том әзерләгән. Мон-нан тыш егетләргә җылы оекбаш, пир-чәткә, дарулар да юлланганнар. Чараны «Татарстан хатын-кызлары» төбәк иҗти-магый оешмасы оештырган.

Һәркем булыша ала

Донецк Халык Республикасының Волнова-ха шәһәре халкына ярдәмгә ашыккан Чал-лы егете Илдар Гайсин бернича көн элек туган шәһәренә әйләнеп кайтты. Биредә җирле халыкның җимерелгән йортларын төзекләндерүдә катнашкан ул. Йөрәк куш-канга алынган Илдар бу эшкә.

– Әтием 17 яшендә Бөек Ватан су-гышына киткән. Әнием ягыннан Гыйль-мегаян бабам да сугышта катнашкан, яу кырында ятып калган. Шул рәвешле су-гыш безнең гаиләдә тирән эз калдырды. Телевизордан Донецкидагы җимерелгән йортларны, чарасызлыктан күз яше түк-кән әби-бабайларны күрдем дә, шул вакытында шунда китеп, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә карар кылдым, – ди Илдар Гайсин. – Волноваха шәһәрендә җимерел-гән кафеда яшәдем. Анда ут, су, ятып йок-ларга раскладушка бар иде. Авыр булача-гын белдем. Әмма бу эшне башкарып чы-гуыма бик сөенәм.

«Татар-информ»

КӨТӘР КЕШЕҢ БУЛГАНДА...

ИГЕНЧЕ ӨМЕТЕ

Чистай

«Хәзерге акылым булса, авыл хуҗалы-гына борылып та карамас идем. Ә ул чакта яшьлек дәрте, егерлеге алдан йөрткән». 25 ел элек җитәкче вазыйфа-сын калдырып, шәһәрдән авылга кай-тып, фермерлык эшен башлап җибәргән Валерий Захаровның ярым шаярып, ярым җитди итеп әйткән сүзләре бу. Шушы еллар эчендә шактый сынаулар узып, бернинди ярдәмсез, тәҗрибәсез башлаган эшенең матур әҗерен күрә ул бүген.

Валерий Алексеевск районының Рус Майнасы авылында гап-гади гаиләдә туган. Әтисе – терлекче, әнисе сыер савучы булып эшләгән. Авыл таркалгач, гаилә Чистай районының Данауровка авылына күченә. Нәкъ менә шунда яшәгәндә егет авыл хуҗалыгы белән кызыксына башлый да инде. Авыл хуҗалыгы техникумы-на укырга керә, аны тәмамлагач, армиягә алына. Хезмә-тен тутырып кайткач, Чаллыга эшкә урнаша, соңрак йөк күтәрә торган төзелеш краннары буенча участок җитәкче-сенә кадәр күтәрелә. Ул елларда аның кул астында 150 ке-ше була. Ләкин тугыз ел шәһәрдә яшәгәннән соң, ул адым ясый.

– 1997 елда, фатирдан кала, эшләп тапкан бөтен мил-кемне сатып, авылда үз эшемне башларга булдым. Ялкынп чак, теләкләр зур, ә баш юк. Бүгенге акылым булса, бо-рылып та карамас идем югыйсә, – дип көлә ул кетер-кетер. – Шулай итеп, бүл-бүш 15 гектар җирдә эш башларга бул-дым. Авыл хуҗалыгын күргән бар ла ул, колхоздагы кебек эшләрмен әле, дип кайтып кердем авылга. Ләкин бөтенләй башкача килеп чыкты. Авырлыклар бик күп иде. Бернәрсә дә юк, барысын да сатып алырга кирәк. Дачаны сатып – орлык, гаражны сатып – трактор, базны сатып, чәчкеч ал-дым. Хәзерге тәҗрибәм һәм акылым белән уз-үзәмә шак-катам. Ул чакта нинди уңыш турында сүз булсын? Ләкин мин ныклап тотынган һәм уңышлы юл сайлавыма чын күңелдән шашнган идем.

Ул чагында ире кайда – хатыны да ике яшьлек кызлары белән шунда була.

– Хатыным да шушы районныкы иде. Әнисе якын булу да шәһәрдән күченеп кайтуга бер сәбәп булгандыр. Ләкин соңрак хатынның мондый тормыштан арыды, гаиләбез тар-калды. Минем исә әле дә шәһәр белән авыл арасында тузан төшергәнем юк. Эшем авылда булса да, кунарга Чистайда-гы фатирга кайтып йөрим, – ди ул.

Баштагы елларда Валерий бодай үстерә, ләкин ул табыш китерми. Шуннан соң карабодай чәчә. Анысы да өметләрне аклымый. Керемне исә аңа бәрәңге китерә. Аны саткан ак-чага техника, кирәк-ярак ала.

– Мин эш башлаганда, дәүләттән бернинди дә ярдәм булмады. Хәзер бу яктан күпкә яхшырак. Соңрак мин дә грант оттым, ул акчага трактор алдым. Эшләр шактый җиңеләйде, – ди ул.

Шулай итеп акрынлап чәчү мәйданнарын, техниканы арттыра. Бүген ул 900 гектардан артык җирдә эшли. Фер-мер хуҗалыгында безнең өчен гадәти булган, күнегелгән арпа, бодай, карабодайдан кала житен, сафлор, ачы торма культуралары да үсә. Соңгысы безне аеруча кызыксын-дырды, чөнки аны хуҗалыкларда бик сирәк очратырга ту-ры килә. Валерий Захаров әйтүенчә, ачы торманың орлы-гын аралап, чит илгә саталар икән. Гомумән алганда, аны сидерат (туфракны сыйфатын яхшыртя торган үсемлек) буларак кулланалар. Аеруча җирне сөрмичә генә эшләүче хуҗалыклар өчен яхшы, чөнки ачы торманың тамырлары тирәнгә үтеп, туфракны йомшарта. Нәтиҗәдә дымлылык яхшы саклана. Моннан тыш, әлеге культурадан космето-логиядә кулланыр өчен май ясыйлар. Гади халык исә аны бакчада чүп үләннәргә каршы көрәшүдә файдалана. Ягъ-ни ачы торма «бакча санитары» буларак хезмәт итә.

– Ләкин миңа ул ашлык буларак кызыклы. Доллар түбәнгә тәгәрәгәнче, бәясе шәп иде, – ди фермер. – Мин аны өч ел элек кенә куреп алып чәчкән идем. Узган ел уңышы начар булды. Быел уңышы яхшы, ләкин доллар төште. Житенне дә узган ел гына утырттым. Шулай ук был-тыр аны үстерү отышлы булган иде. Европадагы заводка тапшырдык, быел анысы да сынатты. Сафлор – минем өчен шулай ук яңа культура. Аны Татарстанда бик сирәк кеше утырта. Аның тамыры тагын да тирәнгәрәк төшә, бөтенләй халсезләнгән, сыйфатсыз туфракка да утыртып була.

Фермер фикеренчә, авыл хуҗалыгында акчаны төрле кәрҗиннәргә салырга кирәк.

– Төрле культуралар утыртып, дөрес эшләгәннәрдән дип уйлыйм, чөнки быел бөртекләрдә бәя түбән. Доллар төшсә дә, барыбер маржиналь культуралар үстерү отыш-лырак. Еллар һәм тәҗрибә бер генә культура белән түгел, ә төрлеләр белән эшләргә кирәклеген өйрәтте. Берсе уңмаса, икенчесе коткара, – дип фикерли Валерий Захаров. – Авыл хуҗалыгында өмет яшәтә. Игенче һәрвакыт, киләсе ел яхшырак булыр, дип өметләнә. Узган ел уңыш булмады, со-рау зур, тик сатарга әйбер юк иде. Быелга зур өмет багла-дык. Быел уңышы бар, акчасы юк. Шуңа күрә мин, колхоз-чының ике баш бәласе бар, дим: уңыш һәм уңыш булмау.

Зөлфия Хәлиуллина

Валерий әйтүенчә, үзенең уңыш серен ул үз вакытында күрсәткән тәвәккәллегендә, уңгатлегендә, максатчанлы-гында һәм яңалыктан курыкмавында күрә.

– Безнең эштә тәвәккәллектән башка булмый. Мәсәлән, сафлорның нинди культура икәнен белми идем. Ләкин тәвәккәлләп, аны 800 кг утыртып карадым. Ул чагында бу культурага гербицид юклыгын белми идем әле. Тагын бер тапкыр тәвәккәлләп, моңа кадәр беркем дә кулланып кара-маган гербицид белән эшкәртеп карадым. Нәтиҗәдә 40 тонна сафлор җыеп алдым. Бу культура талымсыз булып чыкты. Ә куркуны җиңә алмаган булсам, бу турыда белмә-гән дә булыр идем, – ди ул.

Шунысы кызыклы: «бу юлга кире әйләнеп кайтмас идем» дип башлаган сөйләшүебез «күңелем кушкан эшне эшләвем белән бәхетлемен» дип тәмамланды.

– Мин бит өч ел Чаллыдагы фатирымны сатмый тор-дым, – диде ул. – Теләсә кайсы вакытта барысын да ташлап, кире китә ала идем. Эшемдә дә ахырга кадәр көттереп. Ләкин сайлаган юлдан борылмадым. Шуңа күрә үземне бәхетсез дип әйтә алмыйм. Бүген мин үз-үземә хуҗа, яраткан эшем белән шөгыльләнәм. Барысы да шома гына бармый, әлбәттә, ләкин холкым көчле. Кайбер кешеләр эшкә акча өчен генә йөри, ә мин барысын да күңелем куш-канга эшли алуым белән бәхетле.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЙДА ИКӘНЕҢНЕ БЕЛӘМ...

Җиңүчеләр

Бөек Ватан сугышында фашистларга каршы көрәштә окопларда, снаряд чокырларында билгесез ятып калган ватандашларыбызның исемнәрен кайтару йөзеннән «Кайда икәнеңне беләм…» (Теперь я знаю, где…) дип аталган яңа проект эшли башлады. Аның максаты – меңнәрчә кешегә, бигрәк тә яшь буынга ата-бабаларының яу кырында ятып калган урыннарын табарга ярдәм итү. «Хәрби Дан клубы» Татарстан Республикасы ассоциациясе рәисе Михаил ЧЕРЕПАНОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Михаил Валерьевич, сез инде бу җәһәттән 1988 елның 9 маенда ук Советлар Союзы халкына «Синең исемең билгесез» дигән мөрәҗәгать белән чыккан идегез. Бер караганда, эшләнгән эшләр дә күп кебек, әмма, ни кызганыч, сугыш кырында ятып калган солдатлар исемсез кала бирә. Инде тол калган хатыннарга ярдәм итү турында сүз алып барырга, бәлки, соңга да калдык кебек. Бер дә булмаса, балаларына, оныкларына «сезнең әтиегез (бабагыз) хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булды» дигән сүзләр язылган белешмәне кем бирергә тиеш?

– Сүз дә юк, беренче чиратта районнардагы хәрби комиссариатлар эше бу. Әмма андагы штат расписаниеләрендә әлеге үтә дә вак эшне алып баручылар каралмаган. Югыйсә, бу очракта уннарча гына түгел, йөзләрчә мең һәлак булган, хәбәрсез югалган кеше турында сүз бара бит.

Татарстан Республикасының электрон Хәтер Китабындагы мәгълүматларга карасак, 1941–1945 елгы Бөек Ватан сугышы чорында фронтка 700 меңнән артык кеше алынган, шуларның 375 меңе әйләнеп кайтмаган. 100 меңнән артык гаилә фронтка киткән туганы турында «хәбәрсез югалган» дигән хат кына алган.

Уйлап карасаң, сугышта һәлак булган солдатның туып кына калган баласына да хәзер 80 яшь тирәсе бит инде. Тиздән исән булган оныклары да бик аз санда гына калыр кебек.

:: Бу җәһәттән республикада ниләр эшләнә?

– Республика җитәкчеләре әлеге мәсьәләнең мөһимлеген аңлап эш итә. Һәр районда төбәк электрон Хәтер Китапларын булдыру өчен эшче төркемнәр төзелә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча «Хәрби Дан клубы» алып барган эзләнүләр нәтиҗәсендә соңгы өч елда гына Россия Оборона министрлыгы архивларында һәм сайтларында 37000 тирәсе якташыбызның язмышын ачыклый алдык. Моңа кадәр алар барысы да билгесез булып исәпләнгәннәр. Шунысы сөенечле: тәҗрибәбезне өйрәнеп, безгә башка төбәкләр дә кушыла. Мәсәлән, Мари Иленең «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» региональ иҗтимагый оешмасы 5 елдан артык эшли (2020 елда юридик статуслы булды). Җитәкчесе Сания Газизҗанова белән бергә без «Россиядә сугыш кагылмаган гаилә юк…», «Игелекле исемен кайтарырга» дигән проектларны Россия Президенты грантлары фонды һәм «Добрая Марий Эл» хәйрия оешмасы ярдәме белән алып барабыз. Һәр атна шимбә һәм якшәмбе көнне Мари Иле радиосы «Татар теле сәгате»ндә (көндезге сәгать 15.00 – 16.00 кадәр) эзләп табылган татар солдатлары турында мәгълүматларны тапшырабыз. Солдатларны эзләү эшләре дәвам итә. Кызганыч, вакыт беркемне дә аямый. Әле күпме гаилә туганнары турында берни дә белми.

:: Бәлки, хәрби комиссариатлардан тыш башкалар да ярдәмгә килә алыр иде?

– Бу эшкә студентларны, мәктәп укучыларын җәлеп итәргә кирәк дип саныйм. Аның әллә ни авырлыгы да юк. Бары тик Россия Оборона министрлыгының «Память народа», «ОБД-Мемориал» дип аталган сайтларында гына утырырга кирәк.

:: Мин үзем дә бу сайтларда еш утырам. Бер өйрәнеп киткәч, әллә ни кыенлыгы, чыннан да, юк кебек. Шулай да эшне башлаганда бигрәк тә нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк? Нинди киңәшләр бирер идегез?

– Хәзер яшьләрнең фикерләве бик үзенчәлекле. Бер төшенеп алсалар, тиз генә өйрәнеп китүләренә иманым камил. Шуны гына әйтәсем килә: исем-фамилияләр (бигрәк тә татар милләтеннән булганда), авыл исемнәре, хәтта туган еллары, чакыру вакытлары да аңлашылмаслык дәрәҗәдә үзгәреп беткән булырга мөмкин. Мәсәлән, Вәлиевне «Валяев» дип, Вәлиәхмәтне «Вәли» яки «Әхмәт» дип кенә язсалар, бер дә гаҗәпләнмәгез. Әле киң таралган рус исемнәре дә хаталы язылган. Владимир «Володимер» булырга мөмкин. Чакырылган урыннар буенча да хаталар күп. Мордовияне «Молдавия» дип язу, Мари Иле Республикасын Төрекмәнстандагы Марый өлкәсе белән бутау – гадәти күренеш. Шуңа күрә һәр вариантны җентекләп карарга, чагыштырырга кирәк. Кызганыч, күпме утырып та, эзләгән кеше табылмаска мөмкин, чөнки сайттагы исемлекләр тулы түгел.

:: Табылган очракта исем-фамилияне электрон Хәтер Китабына кертү белән эш төгәлләнәме?

– Безнең өчен иң мөһиме – яңа исемнәрне хәрби комиссариатларда, муниципаль органнарда теркәтү. Бу максаттан Хәтер маршлары үткәрәбез. Табылган солдатларның исемлеге район, республика газеталарында басыла, алар турында радиодан сөйләнә, туган якны өйрәнү музейларына, ветераннар советларына мәгълүматлар җибәрелә. Гадәттә шушы чаралар үткәрелгәч, һәлак булган яки бүләге табылган солдатларның туганнары безгә шалтырата башлый. Документларны тантаналы шартларда тапшыру өчен очрашулар оештырабыз. Мондый чараларда мәктәп укучыларының катнашуы төп шарт булып тора.

:: Боларга өстәп, хәзер инде яңа проект – патриотик туризм буенча зур эш башларга җыенасыз...

– Исәннәрнең – кадерен, үлгәннәрнең каберен бел, дип юкка гына әйтмиләр. Әби-бабайларның каберләрен карап, чистартып тору – ул бөтен дөнья халкы өчен уртак гореф-гадәт. Хәзер бер минутка гына уйланып карыйк әле: һәрберебез дә әби-бабаларыбызның, якын һәм ерак туганнарыбызның кайда җирләнгәнен беләбезме, каберләрен зиярәт кылабызмы? Дәшми калучылар, мөгаен, күп булыр. Монысы бит тыныч тормышта. Ә инде «сугышта хәбәрсез югалды» дип хат алганнар турында уйлыйсы да юк. Соңгы елларда патриотик тәрбия формасы буларак «Үлемсез полк» акциясе киң таралды. Балалар һәм яшьләр башта сугышта катнашкан туганнарының фотоларын эзләп мавыктылар. Аннан инде язмышларын ачыклый башладылар. Кызыксыну артканнан-арта бара. Димәк, «Кайда икәнеңне беләм…» проекты бу акция белән турыдан-туры бәйле. Эзләнүләрнең соңгы нәтиҗәсе – хәбәрсез югалганнарның күмелгән урыннарын табу бит.

:: Бүгенгә ниләр эшләнде?

– Эшче төркем төзелде. «Кайда икәнеңне беләм…» акциясенең максаты – меңнәрчә кешегә ата-бабаларының, туганнарының кайда җирләнгәнен табу гына түгел, барырга мөмкинлек булмаган очракта бу урыннарны картадан яки интернеттан булса да табарга ярдәм итү. Сүз дә юк, әгәр дә инде изге җирне карап кайтырга уйласалар, булдыра алган кадәр барлык мөмкинлекне файдаланырга тырышабыз. Бу, әлбәттә инде, күмелгән урынны таптың да шуның белән эш бетте дигән сүз түгел. Оештыру эшләре бик катлаулы: башта җирле хәрби комиссариат, хакимият, волонтерлар, эзтабарлар, диаспоралар белән элемтәгә керергә кирәк.

Туганы сугыш кырында югалган һәр кешене без бу акциядә катнашырга чакырабыз. Бу балаларыбызга патриотик тәрбия бирүдән тыш, күп гаиләләрне бер йодрыкка төйнәр иде. Хәтер дигән нәрсә ул бик зур көчкә ия: төрле дин тоткан, сәяси карашы төрле булган кешеләрне дә берләштерә ала. Төрле милләт вәкилләре арасындагы аңлашу турында әйткән дә юк. Бу гайре табигый хәл түгел: туганнар каберлегендә алар барысы да бергә ята бит. Акцияне тора-бара Россиянең барлык төбәкләренә дә таратырга кирәк дип уйлыйм. Зур чыгымнар да сорамый бит ул. Моны 7 яшьтән 70 яшькә кадәр булган волонтерлар да эшли ала. Ә оештыру эшләрендә ярдәм кулы сузу – безнең бурыч. Мөрәҗәгать итү өчен адресыбыз – echovoyni@yandex.ru

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЮГАЛМЫЙ БАТЫРЛЫК

Зәй

Бөек Ватан сугышында һәлак булган Әкмәл Кашаповның батыр исеме 81 елдан соң туган ягына – Зәй районының Сармашбаш авылына кайтып ирешә. Бу көннәрдә ул яшәгән йорт диварына аның хөрмәтенә истәлек тактасы урнаштырдылар. Әкмәл Кашапов алып өлгермәгән Кызыл Байрак ордены таныклыгын быел язын район хакимияте аның сеңлесе Гыйздениса Миңнехуҗинага тапшырган иде.

Зәй районыннан Бөек Ватан сугышына 11 меңнән артык ир-егет китә. Сармашбаш авылында яшәүче Шәмсениса белән Кашафетдин Кашаповлар гаиләсеннән өч ул – Фәттахетдин, Әкмәлетдин, Мәслахетдин яу кырына чыгып китә. Сугыш башланганчы Әкмәл Екатериновка авылында җиде класс белем ала. Хисапчылар курсын тәмамлый. Зәй районының финанс бүлегендә эшли. Армия сафларына алынгач, Ленинград пехота училищесында кече командирлыкка укый. Сугыш башлангач, Карелия фронтында 52 нче укчылар полкында взвод белән җитәкчелек итә. Әкмәл Кашапов бирегә 1941 елның 7 июлендә «Чертов перевал»га таба чигенүче дошман юлын өзү өчен җибәрелә. Чираттагы бәрелештә рота командиры яралангач, җитәкчелек аның кулына күчә. Ротасы белән штурмга күтәрелә, шәхсән үзе дошманның бер снайперын юк итә, пулеметын сафтан чыгара.

zainsk.tatarstan.ru

Әлеге батырлыгы өчен ул Кызыл байрак ордены белән бүләкләнә. Тик дәрәҗәле бүләген алырга өлгерми, батырларча башын сала. 62 кыю сугышчы дошманның 200 кешесен юк итеп һәлак булалар.

– Әкмәл абый эшкә үҗәт, укырга хирыс, авылның абруйлы, гармунчы егете иде. Армиягә дә олауларда гармун уйнап китте. Миңа күлмәк бүләк иткәнен, армиягә киткәндә мине күтәреп, кочагына алганын әле дә хәтерлим, – дип искә ала сеңлесе Гыйздениса.

Шулай итеп, Кашаповлар гаиләсенә сугышның башында ук Әкмәлетдиннең батырларча һәлак булуы турында хәбәр килә. Ата-ана бу кайгыдан айный да алмый, ике айдан төп нигезгә Украина фронтында сугышкан Фәттахетдиннең, 1942 елда Мәскәү астында барган сугышта һәлак булган Мәслахетдиннең үлеме турында кара мөһерле хат килеп ирешә. Әниләре Шәмсениса бу кайгыдан сулып кала, сагыштан аны уллары Гыйльмулла, Сәхабетдин, кызы Гыйздениса аралый.

Илгә Җиңү килгәч, Сармашбаш авылына бер-бер артлы сугышчылар биек Ялантау тавыннан төшеп кайта. Кашаповлар гаиләсенә кайтыр солдат юк. Ләкин сугыш бетеп, ике ел узганнан сон, Гыйздениса әлеге таудан аркасына биштәр аскан бер солдатның кайтып килүен күрә. Ул тау итәгенә төшәрәк кызулый төшә, кулын изәгән итә. Кемнәргәдер сөенеч була бүген, дип кызыгып, ишегалдына керә кыз. Һәм көтмәгәндә йортка әзмәвердәй гәүдәле Фәттахетдин килеп керә, әниләре Шәмсениса аны күреп һуштан язып егыла. Шулай итеп анада яшәүгә өмет, киләсе көнгә ышаныч уяна. Сигез елдан соң туган ягына кайтучы Фәттахетдин Ялантау тавыннан туган авылын, туган йортын күргәндә нинди генә хисләр кичерде икән?! Башта армия хезмәте, Фин, Бөек Ватан сугышлары, әсирлек газабы… Могҗиза белән исән калган Фәттахетдин Аллаһы Тәгаләнең барлыгы, берлегенә инанып, туган як, туган авыл, туган нигез, туганнарның кадерен белеп кайта. Яуда башларын салган ир туганнарын онытмый: Фәттахетдин энесе белән Гыйльмулла өлкән улларына алар исемнәрен кушалар. Буыннар чылбыры өзелми: хәзер илне аларның оныклары саклый.

Рәзимә КАШАПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«5) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.».

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021 елгы салым чоры өчен транспорт салымы исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 октябрь
№ 73-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен **«А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү-техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе коллективына** Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

* * *

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаулары өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: **Әмиров** Руслан Әнвәр улына, **Әнвәр Хассан**га, **Гилев** Александр Сергеевичка, **Гончаров** Александр Александровичка, **Николаев** Тимур Ривкать улына, **Ожерельев** Иван Сергеевичка, **Сәгъдиев** Илдар Рәмис улына, **Салов** Дмитрий Сергеевичка, **Семенов** Андрей Геннадьевичка, **Серебряков** Андрей Дмитриевичка, **Соболевский** Алексей Ивановичка, **Стариенко** Денис Александровичка, **Тәхиятов** Мулланур Зиннур улына, **Фәттахов** Линар Мансур улына, **Щипачев** Денис Андреевичка, 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы массажчысы **Данилов** Александр Владимировичка, 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында югары күрсәткечләргә ирешүе өчен **«Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы коллективына,** 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында югары күрсәткечләргә ирешүе өчен **«Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы коллективына,** 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә өлеш кертүләре өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы хезмәткәрләре: менеджер **Әсәдуллин** Марсель Хатыйп улына, бухгалтер **Кыямова** Ләйлә Әхтәм кызына, физик әзерлек буенча тренер **Тимина** Вероника Владимировнага, массажчы **Ширяева** Елена Александровнага, 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаганнары өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: ярымсакчы **Григорьева** Александра Дмитриевнага, һөҗүмче **Гобәйдуллина** Эльза Наил кызына, ярымсакчы **Дусаева** Алинә Альберт кызына, һөҗүмче **Ефимова** Елена Ивановнага, ярымсакчы **Хәсәнова** Камилла Рамил кызына, сакчы **Чепурнова** Виктория Сергеевнага, республикада «Яшь профессионаллар» хәрәкәте конкурсантларын уңышлы әзерләүгә өлеш кертүләре өчен «Таттелеком» гавами акционер җәмгыятенең яңа технологияләр дирекциясе сервис платформаларын эксплуатацияләү үзәге әйдәүче инженеры **Андреев** Владимир Дмитриевичка, «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының административ директоры **Галәветдинова** Алинә Раиф кызына, «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Гарипова** Айгөл Илдус кызына, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең инженерлык компьютер графикасы һәм автоматлаштырылган системалар ярдәмендә проектлар эшләү кафедрасы доценты **Голубева** Ирина Львовнага, «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең «Ворлдскиллс» һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге җитәкчесе **Гурьянов** Игорь Алексеевичка, «Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе остаханәсе мастеры **Казакова** Марина Сергеевнага, «Халыкара сервис көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Леухина** Елена Евгеньевнага, «Вентиляция технологиясе» җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сервис хезмәте әйдәүче инженеры **Поляков** Вадим Владимировичка, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «КНИТУ-КАИ инженерлык лицей-интернаты» махсуслаштырылган укыту-фәнни үзәге директорының фәнни-тикшеренү эше буенча урынбасары **Хәйдәров** Илнар Илгиз улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары **Вәлиуллов** Рөстәм Фәйзрахман улы, халыкны социаль яклау системасын камилләштерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль ярдәм чаралары аудиты бүлеге башлыгы **Пислегина** Эльвира Сәлимҗан кызы, республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле хезмәте өчен **Савельчев** Алексей Петрович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Татэлектромаш» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Исламов** Илдус Зәки улы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе, җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция полковнигы **Галимбәков** Ринат Әнәс улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Баһауов** Айрат Илшат улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Көрәш

Дуслар җиңсен!

Казанда Татарстанның иң көчле көрәш командасын ачыкладылар. Федерация Кубогы өчен узган бәйгедә Лаеш районы өчен бил алышкан егетләр җиңү яулады. Теләче командасы – икенче, Әлмәт көрәшчеләре исә өченче булды.

Көрәш дөньясында үзенә күрә бер яңалыкка әверелгән әлеге ярышның беренчесе узган ел оештырылган иде. Моңа кадәр күп еллар дәвамында уздырылган Авыл хуҗалыгы министрлыгы бәйгесенең урынын алды ул. Урыпҗыю эшләре тәмамлангач, авыл егетләрен Казанга җыя иде министрлык ярышы. Әлеге турнирда көрәшчеләр үз категорияләрендә шәхси җиңү һәм командалар арасында беренче урынга чыгу өчен бил алышса, Федерация Кубогында уртак уңыш мөһимрәк. Хәтта үз ишләрең арасында бер мәртәбә отмыйча да, җиңүчеләр арасына керергә мөмкин. Иптәшләрең синең өчен дә тырышса, әлбәттә. Кыскасы, бердәмлек сорала. Җиде үлчәү авырлыгында оештырылган ярышта уңышка ирешү өчен командадагы ким дигәндә дүрт кешенең көндәшеннән өстен чыгуы кирәк. Эшнең ни белән бетәсе әле соңгы алышлар тәмамланганчы ук ачыкланса, ахырга таба бил алышып тормаска да мөмкин. Шимбә көнне узган бәйгедә андый хәлләр дә булды.

Ярымфиналда Әлмәт белән Түбән Каманы отып, Федерация Кубогы бәйгесенең финалына Лаеш һәм Теләче командалары чыкты. Төгәлрәк әйтсәк, җыелма командалары. Теләче өчен хәзер Рәмис Хәйруллин, Мөхәммәд Хәбибуллин, Артур Зөлкәрнәев, Ренас Кәлимуллин, Айгиз Зәйнетдинов, Раил Нургалиев, Фәрхәт Фәйзуллин бил алыша. Яртысыннан артыгы – тумышы белән башка район, хәтта төбәк егетләре. Лаешның беренче командасында исә барысы да читтән килгән көрәшчеләр: Алексей Абрамов (Алексеевск), Илназ Димиев (Мамадыш), Динар Кәримуллин (Теләче), Раил Сәлахетдинов (Киров өлкәсе), Ранис Галимуллин (Теләче), Муса Галләмов (Мари Иле), Радик Сәлахов (Зәй). Лаеш өчен халыкара класслы 6 спорт остасы тир түкте әлеге бәйгедә! Яхшы күренешме бу, әллә юкмы – һәркемнең үз фикере. Көрәшчеләргә келәм генә түгел, эш һәм аш та кирәк. Ләкин аларның бер командадан икенчесенә күчеп йөрүенә гади тамашачы гына түгел, хәтта хөкемдарлар да өлгерә алмый.

Соңгы елларның иң көчле көрәшчеләреннән саналган Раил Нургалиев, Муса Галләмов һәм Радик Сәлаховның бил алышуы һәр бәйгенең бизәгенә әверелә. Бу юлы тамашачыга андый бәхет тәтемәде. Муса белән Радик хәзер бер командада, төрле категорияләрдә көрәшәләр. Раил белән Муса исә финалда бил алышырга тиеш иде. «Травмасы бар аның», – диде Раил, авызын ерып. Шулай итеп, Нургалиев, көрәшеп тә тормыйча, келәмнән җиңүче булып чыгып китте. Әмма батырлар исемлегенә керә алмады. Чөнки алдагы биш алышта Лаеш командасы 4:1 исәбе белән алга чыккан иде. Хәлиткеч очрашуда Ранис Галимуллин Айгиз Зәйнетдиновны отуга ук Федерация Кубогының биелгы иясе ачыкланды. Өченче урынны Әлмәт командасына бирделәр. Бирделәр, чөнки Түбән Кама егетләре келәмгә чыкса да, көрәшеп тормады. Мондый күренеш тамашачыга ошамады, билгеле, аның каравы фото һәм видеога төшерүчеләр рәхәтләнде. Җиңгән як «чиста алым»нарны шәп ясады чөнки.

...18–19 ноябрьдә көрәшчеләр Татарстан чемпионатына җыела. Монысында шәхси җиңү өчен дә көрәшәчәкләр. Аңа кадәр исә Әлмәттә яшь егетләр арасында бәйге булачак. 29 октябрьдә алар нефтьчеләр башкаласына җыелып, татарның танылган батыры Ильяс Галимов истәлегенә бил алышачак.

ИҢ КӨЧЛЕ 10 КОМАНДА	
1	Лаеш
2	Теләче
3	Әлмәт
4	Түбән Кама
5	Теләче 2
6	Чаллы
7	Зәй
8	Биектау
9	Балтач
10	Кукмара

«Татар-информ»

ШЕКСПИРГА «ХУЛИГАННАРЧА» ҖАВАП

vk.com/kariev_teatri

Премьера

«Үз дигәнен итми калмый сөю...» Ромео һәм Джульеттаның бәхетсез һәм фаҗигале мәхәббәт тарихын һәркем беләдер. Кариев театры исә урта гасырлардагы вакыйгаларга бүгенге күзлектән карарга тәкъдим итә. Мәгънәсез нәфрәтнең ахыры нәрсә белән тәмамланачак? Ике кавем арасындагы каршылыкка нокта куя алырлармы?

Кариев театры яңа театраль сезонның беренче премьерасын тәкъдим итте. Башкортстаннан килгән яшь режиссер Илсур Казакбаев мәңге үлмәс классика – Шекспирның «Ромео һәм Джульетта»сын куйды. Бу – башкорт режиссерының Кариев театры сәхнәсендәге икенче спектакле. Аңа кадәр ул Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» әсәрен куйган иде.

Спектакльнең иҗат төркеме турында берничә сүз. «Ромео һәм Джульетта»ның тексты һәм тәрҗемәсен Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов белән шагыйрә Лилия Гобәева әзерләгән. Рәссам – Санкт-Петербургтан килгән Сергей Кретенчук. Ут буенча рәссам Евгений Ганзбург та – төньяк каладан. Музыка өчен Уфадан Магуля Мезинова һәм Казаннан «GAUGA» төркеме җаваплы булган. Хореограф Ольга Даукаева – шулай ук Уфаныкы. Күргәнегезчә, «безнең» кешеләр бик аз.

16+

Яшь тамашачы театрында куелса да, спектакльнең яшь чикләрен 16+ дип билгеләгәннәр. Шекспирның бу әсәре белән таныш булганнар сәбәбе нидә икәнен чамалыйдыр. Шулай да режиссер аңлатмасын искә төшерик әле.

– «Ромео һәм Джульетта» язылганда яшь чикләүләре дигән төшенчә булмаган. Шекспирның драматургиясе дә балалар яки үсмерләр өчен дип аерылмый. Аның әсәрләрендә үлем бар – моны берни эшләтеп тә булмый. Аның әсәрләрендә мәхәббәт тә бар. Ул мәхәббәтне ничек бар, шулай күрсәтәбез, диюем түгел. Ләкин әти-әниләр төрле бит. «Балама нәрсә күрсәтәсез?!» – диючеләр булмасын өчен, яшь чикләрен 16+ дип билгеләдек, – дип аңлаткан иде Илсур Казакбаев премьерага багышланган матбугат очрашуында.

Шуннан театр директоры Луиза Янсуар: «Монда Илсур-әти һәм Илсур-режиссер шактый каты көрәште», – дип өстәп куйды. Илсур-әти җиңгән, димәк.

Джульетталар

Спектакльдә Ромео роленә Булат Гатауллин, ә Джульетта роленә Казан театр училищесы студенты Алия Фәйзиева һәм Кариев театры актрисасы Рузанна Хәбибуллина билгеләнгән. Кызганыч, икенче Джульеттага бәя бирә алмыйм – премьераның беренче көнендә Алия Фәйзиева уйнады.

Шулай итеп, Булат белән Алия әле 16 һәм 14 яшен генә тутырган, бер-берсенә үлеп гашыйк булган үсмерләрне уйнарга тиеш иде. Саф, самими мәхәббәт тарихын. Башта мәхәббәттән йөзләре алсуланып янды аларның. Ә соңыннан икесе дә тере мәеткә охшап калды. Газаплану, әрнү, бәргәләнүне оста күрсәттеләр. Тик бер-беренә «ятып» бетмәделәр кебек тоелды. Бу ике геройга Шекспир сурәтләгән бербөтенлек җитмәде.

Чынбарлык

Спектакль нәрсә турында? Әсәр белән таныш булганнар бу сорауга җавапны алдан ук белеп килгәндер. Гомумән, тамашачыны классик әсәрләр белән гаҗәпләндерү күпкә авыррак бит ул. Шулай булуга карамастан, Илсур Казакбаев Шекспирның «яңа ачкыч»ын тапкан. Моны ул үзе әйтте. Режиссер фикеренчә, спектакльдә кем нәрсә күрергә тели, кемне нәрсә борчый, кемнең кайсы җире авырта – шуларны күрә.

Фикер

Айдар ШӘЙХИН, галим:
– Башта кабул итү катлаулырак булса, ахырга таба барысы да төгәл, адекват булып формалашып бетте. Шуңа да премьера ошады. Яшь тамашачы театры өчен, 16 яшьтән өлкәнрәкләр өчен туры килә торган спектакль дип уйлыйм. Бу спектакль яшьләрне нәрсәгә булса да өйрәтергә тиеш, дип әйтү кыен. Гомумән, бүгенге җәмгыятьтә театр яшь буынны тәрбияли алмый. Алар, беренче чиратта, медиадан, кино-сериаллардан, телевизордан, дөньяда барган хәлләрдән өйрәнә. Ә театр исә шунда күргәннәрне башка яктан анализларга, аларга бәя бирергә, инде өйрәнгәннәрне бер калыпка кертергә мөмкинлек бирә. Кариевның «Ромео һәм Джульетта»сы бер-беребезгә игътибарлы булырга өнди, дөньяда иң куркыныч нәрсәнең нәфрәт икәнен, аның мәгънәсезлеген күрсәтә.
Режиссерга спектакльнең ахыры өчен аерым рәхмәт. Тетрәндергеч өлеше түгел, нәкъ менә бию белән тәмамланган өлеше өчен. Спектакль трагик нотада тәмамланса, бик начар, авыр тәэсир калдырыр иде. Башта режиссер һәм актерлар безне авыр хәлгә җиткерәләр, борчылырга мәҗбүр итәләр һәм шул рәвешле үзләре керткән авыр халәттән чыгаралар, иркенлек ярдәмендә өмет бүләк итәләр, коткаралар. Бу – бик мөһим. Без моңа карап дөньядагы мәгънәсез нәфрәтнең чиге барлыгына өметләнәбез. Моның символик ягына да игътибар итәргә кирәк. Дөньяда нәфрәт ничек кенә күп булса да, без аны күрмәмешкә салышабыз, җырлыйбыз, биибез. Бу элек тә шулай булган, шулай булачак та.

Һәм ул шулай булды да. Ике яшь йөрәк арасындагы мәхәббәт тарихының нәкъ менә хәзер куелуы аңа бөтенләй башка төсмерләр өстәде.

Билгеле булганча, әсәрдә Монтекки һәм Капулетти кавемнәре үзара дошманлашып, сугышып яши. Спектакль дә шул турыда бәян итүдән башлана. Кариевларның «Ромео һәм Джульетта»сы тарихын кулына микрофон тотып Язмыш (Алсу Шакирова) сөйли. Мәб, ягъни феялар королевасы була инде ул. Язмыш ике кавем арасындагы сугышларның корбаннарын әйтә тора, алар арта торалар. Сәхнәнең арткы планында һәр геройның сурәте белән планшетлар урнаштырылган. «Кан коелган» саен бер планшет сүнә бара. «Тагын бер корбан. Меркуцио, 14 яшь». Язмышның бу сүзләреннән соң тәннән суык йөгерә. «GAUGA» төркеменең җырлары бу сүзләрнең тәэсирен арттырды гына. Бу төркем ярдәмендә сәхнәдә чын мәгънәсендә гауга хөкем сөрә.

Язмыш алдан ук, бу ике кавем арасындагы озак елларга сузылган каршылыкка балаларының үлеме генә нокта куячак, дип әйтеп куя. Шекспирда да Монтекки һәм Капулетти кавемнәре дошманлыклары турында балаларының җеназалары янында гына оныта. Ә Илсур Казакбаев оныттырмый һәм бу ике кавемне дуслаштырмый. Язмышның ачы тавышлар чыгарып кат-кат кычкыруы да ярдәм итми. Монтекки – бер якка, Капулетти икенче якка барып баса. Режиссер аңлатканча, болай дөреслеккә күбрәк туры килә.

«Ромео һәм Джульетта» тарихы әнә шулай тәмамланды. Ә спектакль – юк. Соңгы сүзләрдән соң сәхнәнең нәкъ уртасына «GAUGA» чыкты, һәм геройлар, «терелеп», сикерә-сикерә бии башлады.

– Ничек кенә күңелсез булса да, спектакльне күтәренке рухта тәмамлыйсы килде. Кызганыч, ничек кенә тырышса да, театр яшьләрне һәм, гомумән, кешене үзгәртә, тәрбияли алмый. Бик аз дәрәҗәдә булса гына. Шуңа да безнең һич югы яхшы эмоцияләр бүләк итәсе килде, – дип аңлатты Илсур Казакбаев.

Яшьләргә ошар бу спектакль. Динамикасы, яңгыраган җырлары, «хулиганлыгы» белән җәлеп итәр ул, мөгаен. Шул ук вакытта нәфрәт һәм дошманлыкның беркайчан да яхшыга илтмәячәген төшендерсен иде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе, әтисе

ВӘЛИУЛЛИН Камил Шәфыйк улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектларын эшләү бүлеге баш киңәшчесе Вәлиуллина Лилия Камил кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү (Гостехнадзор) идарәсе җитәкчесе

ЗИАТДИНОВ Радик Рәгыйп улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе җитәкчесе

ЗИАТДИНОВ Радик Рәгыйп улы

кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Сарман муниципаль районы хакимияте, Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе җитәкчесе

ЗИАТДИНОВ Радик Рәгыйп улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ЕРАК АРАНЫ ЯКЫН ИТЕП

«КҮҢЕЛ» РАДИОСЫ 25 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ

«Күңел» радиосы Казанда туксанынчы елларның яшьлек җырларын яңгыратты. «Безнең яшьлек еллары» дип аталган концертта татар эстрадасының популяр җырчылары «алтын» хитлары белән тамашачының күңелен күрде.

Җырлы бәйрәм радионың 25 еллыгы һәм «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең 15 еллыгы уңаеннан үткәрелде. Дүрт сәгатьтән артык дәвам иткән концерт Казан тамашачысы өчен чын мәгънәсендә зур музыкаль бәйрәм булды. 80–90 нчы елларда популяр булган җырларны тыңларга меңләгән кеше җыелган иде.

Бәйрәм кунакларын Татарстан Дәүләт Советы депутаты Камил Нугаев сәламләде:

– «Күңел» радиосына – 25 ел! Чирек гасыр узган. Бүген монда безнең яшьтәшләр, безнең чор кешеләре җыелган. Чаллы һәрвакыт яшьләр шәһәре булды, гөрләп торды. 1997 елда оешкан «Күңел» радиосы да татарның иң гөрләгән чагында барлыкка килде. Ул вакытта Чаллы һәм якын-тирә районнар тыңласа, бүген аны республикада гына түгел, башка төбәкләрдә дә тыңлыйлар.

«Күңел» радиосы җитәкчесе Лилия Мәхмүтова әйтүенчә, 25 еллык тарихы булган радио, ниһаять, беренче тапкыр башкалада имтихан тотты.

– Әгәр безнең миллионлаган тыңлаучыбыз, сезнең кебек кадерле тамашачыларыбыз булмаса, без бүген бу сәхнәдә басып тора алмас идек. Барыгызга да чиксез рәхмәтемне белдерәм. Ике арадагы күпер җимерелмәсен. Киләчәктә дә бер дулкында калыйк, – диде ул.

Дүрт сәгатьтән артык барса да, концерт бер сулышта узды. Тамашачылар яраткан артистларына кушылып җырлады һәм күңел ачты. Бәйрәм концертында татар эстрадасының легендалары һәм популяр җырчылары – Зәйнәб Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов, Рөстәм Закиров, Гөлдания Хәйруллина, Асаф Вәлиев, Асылъяр, Рәсим Низамов, Зөһрә Шәрифуллина, Айрат Гомәров, Илназ Минвәлиев, Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар, «Мунча ташы» эстрада театры артистлары, Рамил Миндияр, Зөфәр Хәйретдинов, Виталий Агапов, Руслан Кираметдинов, «Айфара» төркеме, Әлфинә Әзһәмова катнашты.

Концертта шулай ук 18 елдан соң беренче мәртәбә сәхнәгә чыгучы «Заман» төркеме егетләренең берсе Айрат Гомәровны, әтисе Дәниф Шәрәфетдинов урынына җырлаган Динар Шәрәфетдиновны, «Керәшен бароны», Татарстанның халык артисты Виталий Агаповны да ишетергә мөмкин иде. Әтисенең «Зур юлларга чыкты атым» һәм «Сагыну хисе» хитларын башкарган Динар Шәрәфетдиновны тамашачы яратып кабул итте, аны көчле алкышларга күмде.

«Айфара» төркеме дә тамашачыларга үзенең ретро хит җырларын бүләк итте. «Брежнев заманыннан бирле җырлыйбыз. Брежнев юк, без бар әле», – диде елмаеп, «Айфара» төркеме солисты Алмаз Шәрифуллин. Алар башкаруындагы «Ак каен» җыры беркемне дә битараф калдырмагандыр.

Сүз уңаеннан, концерттан кергән акчаның бер өлеше хәрби бурычларын үтәргә киткән ир-егетләргә кирәк-ярак, җылы киемнәр алуга тотылачак. Кичәдә дә мобилизация темасы күтәрелде. Әйтик, Татарстанның халык артисты Асаф Вәлиев хәрбиләргә багышлап «Әйләнеп кайтыгыз» җырын башкарды. Тамашачының гына түгел, җырчының да күңеле тулды шул мизгелдә. Хәер, ул моны яшермәде дә.

Ләйсән САФИНА

«Татар-информ»

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 357

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+